РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

«16» февраль 2026 ел                                                                 № 25

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Советы
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы регламенты турында» 2019 елның 5 июнендәге 224 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы «Чирмешән муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советы» ассоциациясенең 2025 елның 30 декабрендәге 1262 номерлы хатын карап, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы регламенты турында» 2019 елның 5 июнендәге 224 номерлы карарына (район Советының 2024 елның 28 маендагы 248 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы Регламенты турында» Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2019 елның 5 июнендәге 224 номерлы карары преамбуласында «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары

турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.2. 33 статьяда:

- 2 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә: «Депутатлар төркеме составы өч депутаттан ким була алмый. Район Советы депутаты бер генә депутат төркеме әгъзасы була ала».

- 10 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә: «Депутат төркеме составында өчтән кимрәк депутат калган очракта, әлеге факт теркәлгән көннән соң 30 көн узгач, әлеге депутат төркеменең эшчәнлеге туктатылган дип санала һәм әлеге депутат төркеме депутат төркемнәре реестрыннан төшереп калдырыла».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Чирмешән муниципаль районы Башлыгы,
Татарстан Республикасы Чирмешән
муниципаль районы Советы рәисе Р.Т. Айбатов

**Черемшанский муниципальный район**
**Республики Татарстан**

**Лист согласования**

| № | Должность, ФИО согласующего | Комментария согласующего | Подпись | Дата согласования |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Заместитель Главы, заместитель председателя Совета района Гумерова Н.Г. | проверено согласовано | | |
| 2. | Руководитель аппарата Совета района Аглиуллин М.Х. | согласовано | | |
| 3. | Начальник организационного отдела Совета района Гайнуллин Ф.Р. | подготовил | | |